ГЛАВА
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.55, с. Введенская Слобода,
422591

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 55 нче йорт, Введенский бистәсе авылы,
422591

Тел.: (84379) 3-11-18, факс: (84379) 3-11-18.

29.11.2021 № 1

На № ______________ от ________________

# РЕШЕНИЕ

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Елизаветино авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Елизаветино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза буласызмы? мәсьәләсе буенча 2021 елның 28 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

- Елизаветино авылында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 46 катнашучы, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан 24 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 24 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Елизаветино авылында халык җыены булып узды, халык җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

. «Югары Ослан муниципаль районы районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Елизаветино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән билгеләнгән гражданнарның ташламалы категориясеннән тыш, балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле

əһəмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза буласызмы?
- Елизаветино авылында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау

2" дигән сорау буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Елизаветино авылында гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Введенский Бистәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Д.В. Морозов